ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БОРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

06.10.2020　　　　с. Татарское Бурнашево　　　　5

Югары Ослан муниципаль районы Татар Борнашы авыл җирлегендә гражданнар җыенында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 31 октябрендә 11 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Татар Борнашы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2020 елның 31 октябрендә 14 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Татар Борнашы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 этап: Татар Борнашы авылы, Беренче Май, Октябрь урамнарында яшәүчеләр

2 этап: Татар Борнашы авылы, Совет урамы, Мәктәп урамы, Яңа урам, Молодежная урамы, Луговая урамы, Имәнлек урамында яшәүчеләр

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы:

- Татар Борнашы авылында балалар мәйданчыгын төзү

«ӘЙЕ»　　　　　　　　«ЮК»

5. Халык җыеннарын үткәрү:

1 этап: Татар Борнашы авылының Беренче Май урамы буенча 48-нче номерлы йорт янында

2 этап: Татар Борнашы авылының Совет урамы буенча 58нче йорт янында.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге　　　　　　　　С. В. Бурукин